ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«12» декабрь 2022 ел № 312

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү комиссиясе составын раслау турында

Штаттагы үзгәрешләргә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләрне башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында ташучыларга субсидияләр бирү буенча комиссиянең беркетелгән составын расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 09.12.2021 № 406 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә шәһәр яны юлларының муниципаль маршрутлары буенча автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында" 2022 елның 18 октябрендәге 247 номерлы карары;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының 09.12.2021 № 406 карарының 1 пунктындагы өченче абзацы «атарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга

бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү тәртибен раслау турында».

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz/tatarstan/ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (https://pravo.tatarstan/ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары вазыйфаларын башкаручы К.М. Сотовка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **Р. Р. Шәрипов**

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетынын
12.12.2022 № 312
карары белән расланды

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә шәһәр яны автомобиль транспортының муниципаль маршрутлары буенча җайга салына торган тарифлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыруга бәйле эшләр башкаруга чыгымнар өлешен каплау максатларында йөртүчеләргә субсидияләр бирү комиссиясе составы

Комиссия рәисе-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе;

Комиссия рәисе урынбасары-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары;

Комиссия секретаре-Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлегенең баш белгече;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районынын Финанс-бюджет палатасы рәисе (килешү буенча);

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын төзелеш, архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын Икътисадый үсеш бүлеге башлыгы;

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетынын муниципаль ихтыяжларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу секторы мөдире.